**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

БОЕРЫК

21.03.2018 Казан шәһәре № 134

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 24 февралендә кул куелган 103 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм яклар конфликтын көйләү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы комиссиясе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 11 декабрендә Татарстан Республикасы Президентының УП-1092 номерлы «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турындагы» Указы чыгу белән бәйле рәвештә

боерам:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 24 февралендә кул куелган 103 номерлы боерыгы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм яклар конфликтын көйләү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы комиссиясе турында Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), аңа түбәндәге эчтәлектәге 16.6 пунктын өстәп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«16.6. Әлеге Нигезләмәнең 16.1, 16.3 һәм 16.4 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» подпунктының һәм «д» подпунктының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр яки белдерүләрдә язылган мәгълүматны;

б) соратып алу нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүматны;

в) әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» подпунктының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» подпунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр яки белдерүләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗәне, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 23, 24.2, 25.2 пунктлары буенча карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәрне».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр В.А.Леонов